*№2 декабрь, 2017*

# Гимназия сулышы

***25 нче гимназия укучылары газетасы***

*Яңа 2018 нче ел белән, дуслар!*

*Укуда һәм хезмәттә уңышлар, сәламәтлек һәм бәхет телибез!*



## Бүгенге санда


- “Икмәк заводына бардык”,  8 нче Б сыйныфы укучысы Заһитова Зарина язмасы, 1-бит
- “Әниләр көне”, гимназиядә узган бәйрәмнән репортаж
- “Без театр яратабыз”, 10нчы Б сыйныфыннан Сәетгәрәева Камилла язмасы, 3-бит.
- “ Хәйрия акциясе”, 7нче Г сыйныфы укучысы Хуҗҗәтов Гадел язмасы,2-бит
- “Нәрсә? Кайда? Кайчан?”, 7нче Г сыйныфы укучысы Әхтәмова Динара белән интервью
- “Биючеләр –сәхнәдә”, 6нчы А сыйныфыннан Гыйльманова Алия хәбәре.
- “Әкияттә кунакта”, 6 нчы Д сыйныфы укучысы Зарипова Диана язмасы
- Яңа ел белән!

## Икмәк заводына бардык



Профессиональ ориентация буенча сыйныф җитәкчебез Сиринә Галләмовна Махиянова шактый эшләр башкара. Шушы максат белән ул безне “Түбән Кама икмәк комбинаты”на экскурсиягә алып барды. Без биредә күпереп торган икмәкнең өстәлебезгә килгәнче нинди юллар үткәнен күрдек. Икмәк пешерүче апалар безне яңа пешкән хуш исле икмәк белән сыйладылар. Кондитер эшләнмәләре цехында безне пирожный ясау серләренә өйрәттеләр. Комбинаттагы апа-абыйларны күреп, үз эшеңне яратып, намус белән башкарырга кирәк , дигән нәтиҗәгә килдек. Һәр һөнәр иясе мактауга лаек. Бары тик үз эшеңне яратырга кирәк.

## Хәйрия акциясе



21-23 ноябрьдә гимназиядә “Йортсыз этләргә һәм мәчеләргә ярдәм итик” дигән хәйрия акциясе узды.

Акцияне 8 В сыйныфы укучысы Габдуллина Регина оештырды.



Этләргә һәм мәчеләргә ризык җыюда бигрәк тә 8 В, 8 Г, 2 В, 4 Д сыйныфы укучылары актив катнашты.

Акция барышында җыелган “Kitecat”, “Wiscas”ларны укучылар “Өмет йорты” дигән фондка тапшырдылар.

Бу фондка ярдәм итәргә теләүчеләр, Вокзал урамындагы 26-а йортына мөрәҗәгать итә ала. Хуҗҗәтов Гадел, 7 Г сыйныфы укучысы

## Гимназиядә “Әниләр көне”

Бу көнне гимназиянең актлар залы оста куллы әниләрнең күзне камаштырырлык матур кул эшләнмәләре белән бизәлгән иде. Нәрсә генә юк анда! Бәйләнгән йомшак уенчыклар, төсле кәгазьдән, йон җепләрдән эшләнгән чәчәкләр, искиткеч матур рәсемнәр.



Әниләр өчен гимназия укучылары башкарган мавыктыргыч биюләр, күңелле җырлар бәйрәмне тагын да ямьләндерде.



## Нәрсә ? Кайда? Кайчан?

*7 нче Б сыйныфының интеллектуаль төркеме шәһәр буенча уткәрелә торган “Нәрсә? Кайда? Кайчан?” уенында призлы уеннар алып килә. Уңышка ирешу серләре белән Әхтәмова Динара таныштыра.*



– Безнең команда 2015нче елда оешты. Без - Арина, Әмир, Айдар, Ева, Ринат, Артем һәм мин төп уенчылар. Барыбыз да күпне белергә телибез, “4”ле, “5”ле билгеләренә укыйбыз. Уку елы барышында 8 уен була. Октябрь аенда булган уенда 30 команда арасында шәһәр күләмендә беренче урынны алдык. Гатин Айдар, Спиридонова Арина сорауларга иң төгәл җавапларны бирделәр.



-Динара, сез киләсе уенга ничек әзерләнәсез?

- Без мәгълүматны күбесенчә Википедия сайтыннан эзлибез. Һәрберебезнең яраткан фәне бар: Гатин Айдар - география, Спиридонова Арина- тарих, Джураев Әмир-биология, мин- рус әдәбияты белән кызыксынам. Галимова Ева логик мәсьәләләрне оста эшли.



- Командагызнын нинди традицияләре бар?

-Безнең сыйныф җитәкчесе

Дмитриева Людмила Олеговна уеннарның барышын карый, безне яңа җиңүләргә рухландыра. Уңышлы уеннан соң без кафега барып сыйланабыз.

- Динара, сезнең интеллектуаль төркемегезгә яңа җиңүләргә ирешүне телим!
- Рәхмәт!

## *Отличник булу җиңелме?*

Ничек кенә тырышсам да отличник булып булмады: II нче чиректә дә дүрт “4”лем чыкты. Чын отличник белән сөйләштем әле. Яхшы уку серләрен газета укучыларына җиткерәм.
Яркеев Илья, 6нчы Д сыйныфы укучысы:
- Тырышлык, белемгә омтылыш, өстәмә әдәбият уку, минемчә, иң мөһиме.



Отличник булуымда әти-әниемнең өлеше зур. “Яхшы укысаң, киләчәгең уңышлы булыр”,-ди әнием.Яшьтәшләрем ә гаджетлар белән мавыкмаска, вакытны бушка уздырмаска киңәш итәм!

Муллагалиев Айдар, 8 нче Б сыйныфы укучысы.




## Без театр яратабыз

Безнең гаилә театр сәнгатен бик ярата. Мин,апам һәм әнием белән еш кына шәһәребезнең Туфан Миңнуллин исемендәге татар драма театрына спектакль карарга йөрибез. Бигрәк тә премьералар карарга яратабыз. Соңгы вакытта караган сәхнә әсәре -ул драматург Т.Миңнуллин әсәре буенча куелган “Нәзер”драмасы . Спектакльдә дүрт актер гына уйнады. Анда вакыйгалар сугыш вакытында һәм сугыштан соңгы еллар турында барды. Миңа актерларның уйнавы бик ошады.

Саитгараева Камила, 10нчы Б сыйныфы.



# Туган телне сөючеләр

Уку елы башында укытучыбыз Шарапова Нурия Нәҗиповна татар телендә электрон газета чыгарабыз дип әйткәч, булдыра алырбызмы, дип шикләнгән идек. Түгәрәк утырышларында мәкалә язу, аны корректорлау, фотога төшерү серләре белән таныштык. Һәркемгә номерга креатив материал язарга кушылды.



Газета хәбәрчеләре Гыйльманова Алиянең, Идрисова Азалиянең, Бакирова Алиянең, Гөбәев Булатның язмалары уңышлы булып беренче санда урын алды. Халыкта “Туган телен кадерләгән халык хөрмәткә лаек”, дигән мәкаль бар.

Туган телебез – татар теле яшәсен өчен без,“Гимназия сулышы” газетасы хәбәрчеләре, белемебезне, көчебезне кызганмабыз!

# Биючеләр – сәхнәдә

15 нче ноябрьдә гимназиянең актлар залында 5-10 сыйныфлар арасында бию бәйгесе булып узды. Тамашачыларның көчле алкышларыннан катнашучыларның тырышып әзерләнгән булуы күренә иде. Дәртле, ритмлы музыка сәгать буе яңгырап торды.

Урыннар түбәндәгечә: беренче урында 5нче Б һәм 7нче Г сыйныфлары, икенче урында 5нче г сыйныфының “Стиляги” бию коллективы, өченче урында 6нчы д сыйныфы.

Катнашучылар төрле номинацияләрдә диплом белән бүләкләнде.

# Әкияттә кунакта

Сез беләсезме Убырлы карчык кайда яши? Алабуга шәһәре янындагы урманда аның чып-чын резиденциясе бар икән. Күптән түгел без , 6нчы д сыйныфы укучылары, шунда экскурсиядә булдык.



Әкият геройлары белән бормалы урман сукмакларында төрле сынаулар үттек. Сихри урманда матур чыршы янында Кыш Бабай безгә бүләкләр бирде. Тамашадан соң ашханәдә тәмле коймак белән чәй эчтек. Бу экскурсияне оештырган әти-әниләребезгә бик зур рәхмәт әйтәсе килә.

# Яңа ел интервьюлары



*<u>Аслямова Гузәл Заһретдиновна, гимназиянең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы:</u>*

-Яңа ел якынлашканда күңел ниндидер могҗизалар көтә. Бу елда яхшы укучыларның саны артсын, барысы да "4"ле, "5"ле билгесенә укысыннар, начар укучылар булмасын иде. иде. Барлык кешеләр сәламәт һәм бәхетле булсыннар!

*<u>Шабуров Ильяс Рафаилович, гимназиянең физкультура укытучысы:</u>*



-Мин Яңа елда барлык укучыларга физкультура дәресләренә актив йөрсеннәр дип әйтәсем килә. Хезмәттәшләремнең ял вакытында спорт белән бергә булуларын телим, чөнки "Спорт - сәламәтлек чыганагы".

*<u>Басыйрова Наилә, гимназиянең " Өлкән сыйныф укучылары советы"ның президенты:</u>*

Яңа ел белән котлыйм! Киләсе елның узган елга караганда яхшырак булуын телим. Һәркемнең хыяллары тормышка ашсын иде!




## Яңа елны кайда, ничек каршылыйлар?

Яңа елны һәр илдә дә яраталар, аңа төрлечә әзерләнәләр, һәр ил халкы аны үзенчә каршы ала. Австралиядә Яңа ел 1гыйнварда башлана, бу вакытта анда шулкадәр эссе ди, хәтта Кыш бабай белән Карсылу Яңа ел бүләкләрен су коену костюмыннан таратып йөриләр. Ә Индонезиядә Яңа ел октябрьдә була. Бар халык маскарад киемнәрендә ел буе китергән үпкәләре өчен бер-берсеннән гафу үтенәләр икән. Монголиядә Яңа ел бәйрәме терлекчелек бәйрәме белән туры килә икән. Яңа ел төнендә төрле ярышлар уткәрәләр, Яңа елны безнең кебек чыршы янында каршылыйлар. Кытай Яңа ел вакытында фейерверклар яктысыннан балкып тора.

Редактор:Хужҗәтов Гадел

Проект җитәкчесе:Шарапова Н.Н.